РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_30_» _апрель_________ 2025 ел №_305__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына (район Советының

2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 140 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 156 номерлы, 2024 елның 27 июнендәге 252 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 288 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 4 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 15389 сум тәшкил итә»;

1.2. 1 нче кушымтада III бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәгечә бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 58 процентыннан артмаган күләмдә».

1.3. «Муниципаль район башлыгын, муниципаль районда үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисен акчалата бүләкләү күләмнәре» 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

1.4. 7 нче кушымтаның 1 пунктын бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә ай саен акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи окладның 58 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.»

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2018 елның
24 апрелендәге № 149 карарына
2 нче кушымта

Кушымта
(Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2025 елның 30 апрелендәге
305 номерлы карары
редакциясендә)

Муниципаль район башлыгын, муниципаль районда үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 40 740 |
| Башлык урынбасары | 36 667 |
| Депутатлар | 19 979 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 16 976 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 36 667 |